КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 август г.Казань № 978

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче; 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1280 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1204 нче, 2020 ел, 15 июнь, 491 нче, 2020 ел, 30 октябрь, 975 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1117 нче, 2023 ел, 7 февраль, 115 нче, 2023 ел, 2 май, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында» 2009 елның 15 маендагы ПУ-278 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «махсус компетенциясендәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (Татарстан Республикасы ведомствосы)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «банк учреждениеләрендә исәп-хисап счеты һәм башка счетлар» сүзләрен «казначылык органнарында шәхси счетлар» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел,

26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә.»;

3.2 пунктның егерме бишенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның егерме икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның сигезенче абзацында «, банкларда исәп-хисап һәм башка счетлар ача» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 май, 550 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясенә, 6 бүлекнең дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 328 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 май, 550 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин